**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

Кәрәкәшле ав.

№ 17 23 ноябрь 2016 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум нәтиҗәләре турында» карарын теркәү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 73 маддәсендәге 5 пункты, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законының 60 маддәсенең 3 пункты нигезендә, Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 20 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум нәтиҗәләре турында»гы 59 санлы карарын теркәргә.

2.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең әлеге карарын түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Кәрәкәшле авылы, М.Зәкиев урамы, 47 йорт, шулай ук мәгълүмат стендына эләргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев